*Единство в многообразии*

# ФИКЕР

**Орган Казахстанского конгресса татар и башкир**
**№2 (115) 2018 ел**

**Газета «Фикер» выходила в 1905-1907 гг. при участии Габдуллы Тукая. С 1993 г. выходит в г. Алматы: с 2000 г. под названием «Фикер-Өмет», с 2013 г. -«Фикер».**

==========================================================================



**Елмаеп ул бар галәмгә**
**Башын суза кар астыннан:**
**Тиздән бетәр зәһәр салкын,**
**Язлар килә, дигән сыман.**

**Карлар басып капласа да,**
**Бирешмәгән, туплап көчен.**
**Яктылыкка омтыла ул**
**Жир йөзендә яшәр өчен.**

**Яшим барыбер, дигән күк**
**Умырзая чыга калкып.**
**Шул чәчәктәй мәңге яшәр,**
**Жир йөзендә туган халкым!**

***Тимер Заһит***

## Корея Республикасында үткәрелгән бөтендөнья олимпиада уеннарында 15 яшьлек татар кызы Алинә Заһитова чемпион исемен яулап алды

### Олимпиада чемпионы Алинә Заһитовага

Бу - гүзәллекнең җиңүе,
Матурлык тантанасы!
Бу матурлыкны данларга
Нинди сүзләр табасы?..

Бу - Актаныш гүзәллеге,
Агыйдел матурлыгы!
Бу бит Агыйдел кызының
Матурлык батырлыгы!

Күмелә Гүзәл Кызыбыз
Бар дөнья алкышына!
Ул алкышларга, әлбәттә,
Татарлар да кушыла!

Алинәне мин "Алиһә"
Диеп игълан итәмен!
Бар дөньяга күрсәтте ул
Татарның кем икәнен!..

Бик килә горурланасы!
Бик килә мактанасы!
Бу - татарның зур җиңүе!
Бу - татар тантанасы!



*Роберт Миңнуллин,*
*Татарстанның*
*халык шагыйре*

***Атаклы прозаик, тәрҗемәче һәм тарихчы, Татарстанның атказанган мәдәният эшлеклесе, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Лирон Хәйдәр улы Хамидуллинга 85 яшь тулды***



**РУХИЯТ ЮГАРЫЛЫГЫНА ЧАКЫРУ**

**(кыскартып алынды)**

...Әгәр язма мирасыбызның олылыгы вакыт тарафыннан расланган икән, уртак казанышта өстәмә вазифаларга алынган затларның хезмәте зур. Шулай килеп чыга, элгәрләрдән башланган шушы игелекле традицияне дәвам иттерү танылган әдибебез Лирон Хәмидуллин тәкъдиренә дә йөкләнгән. Бу җаваплы миссияне ул бик уңышлы башкарып килә...

Әтисе Хәйдәр Ленинград камалышын өзү өчен барган аяусыз бәрелештә һәлак булгач, ун яшьлек малай үзеннән-үзе төпкә җигелеп тартырга, ураулы юлларны узарга мәҗбүр ителә. Ул Актүбә тимер юл транспорты техникумына укырга керә...Озаккарак сузылган белем алу барышында исә армия хезмәте сынауларын үтәргә дә өлгерә. Техникумны тоташ бишле билгеләренә генә тәмамлаган Лирон Хәмидуллин тимер юлда бригадир булып эшли башлый, шулай ук Бөтенсоюз политехника институтында читтән торып укуын дәвам иттерә. Кешеләргә җайлы хәрәкәт мөмкинлеге тудыруга бәйле хезмәт аны Орскидан Казанга күченеп килгәч тә ычкындырмый. Ул башкалабызның транспорт идарәсендә инженер, баш инженер һәм партком секретарена йөкләнгән җаваплы вазифаларны башкара, әдәби мохиткә кереп, республика көндәлек матбугатының төрле басмаларында хикәя, повесть һәм очеркларын язып чыгарырга да вакыт таба.

...Минсенергә яратмаучы Лирон Хәмидуллин безнең әдәбиятка моңарчы нечкәләп сурәтләнмәгән яңа геройлар алып килде. Тәнкыйтьче Фәрваз Миңнуллин Лирон Хәмидуллинның үзенчәлеге нидән гыйбарәт соң?- дигән сорауга болайрак җавап бирә: “Иң элек... прозабызның тематик чикләрен киңәйтүдә... Үзе сурәтләгән кешеләрнең эшен, тормышын әйбәт белү аның әсәрләрендәге ышандыру көчен арттыра. Ышандыручанлык һәм тормышчанлык өстенә, аның язганнарында тел белән сөйләп-аңлатып бирүе кыен булган, әмма укучыны иләсләндерә, аның күңелен нечкәртә һәм сафландыра торган үзгә бер моң, күтәренкелек, эчке көй бар”...

Әле Актүбә техникумында укыган елларда ук Лирон Хамидуллин казакъ әдәбиятының тәэссоратлы йогынтысына эләгә. Якынлыгы сизелеп торган казакъ телен егет отыры күңеленә сеңдерә башлый...

Җиңнәрне сызганулы Лирон Хәмидуллин казакъ әдипләре Әнвәр Әлимҗановның һәм Сайын Моратбәковның китапларын татарчага тәрҗемә итеп чыгара. Шулай ук Абайның “Хикмәтле сүз”ен үзебезнең телгә күчерә һәм акынның бер томлыгын төзеп бастыруда катнаша. Аның тәрҗеманлык тырышлыгы белән казакъ язучыларының повестьлары да (“Җәйләүдә”), казакъ халык әкиятләре дә (“Сыбызгы сере”) аерым басмаларда дөнья күрә.

...Әдәби элемтәләрне яңа биеклеккә күтәрүдә Лирон Хәмидуллин үзенчә башлап йөрде. Чагыштырмача кыска вакыт аралыгында Алма-Ата нәшрияты язучыларыбызның дистәләрчә китабын, шул исәптән 1979 елда “Татар повестери” дигән тупламны чыгарды... Татар әдипләренең хикәяләрен русча (“Пробуждение”), үзбәкчә (“Йиллар ва

йуллар”), каракалпакча (“Татар гүррицлери”) махсус басмалар рәвешендә җыйнап-төзеп бастыру, шундый ук жанрдагы әсәрләрдән мадьяр телендә аерым җыентык әзерләү Лирон Хәмидуллинның гаять мәшәкатьле тәрҗемә эшенә җаны-тәне белән бирелгәнлеге хакында сөйли.

Лирон Хәмидуллин үзбәк, каракалпак, башкорт, белорус әдәбиятлары белән тәрҗемә алмашуда да шушы халыкларның мәдәни алгарышын күзалларга ярдәм итәрлек игелекле гамәлләр кылырга өлгерде. Мәсәлән, Әсгать Мохтарның “Чинар”, Василь Быковның “Һәйкәл”, Яныбай Хамматовның “Бөртекләп җыела алтын” китаплары шундый хезмәтләр җөмләсенә керә. Болар янына Александр Капустинның “Беренче җиңүләр”ен дә өстәргә мөмкин...

Сокланмый мөмкин түгел, шуның ише җитди китаплар чыгарган арада Лирон Хәмидуллин көндәлек матбугатта Мохтар Ауэзов,Теләпбиргән Каипбиргәнов, Сырбай Мәүләнов, Мохтар Мәгауин кебек кардәш әдипләрнең әсәрләрен тәрҗемәләп бастырырга да, башка милләт язучыларының татар әдәбиятына кагылышлы хезмәтләрен үзебезнең укучылар хөкеменә тапшырырга яки алдан уйлаган тәртиптә әзерләнгән берәр яңа җыентыкка төпле кереш язарга да җаен таба... Безнең милләтара әдәби багланышларны гамәли үстерүдә Лирон Хәмидуллинга торырлык шәхесләр сирәктер...

Еш кына күренекле әдипләрнең тәфсилләп язылган гыйбрәтле биографияләре дә кешедә чиксез канәгатьләнү хисләре тудырырга мөмкин... Безнең Лирон Хәмидуллин нәкъ менә шушы өлкәдә күркәм нәтиҗәләргә ирешә...

Дәрдемәндкә багышланган хезмәтләр шулай кистереп әйтергә нигез бирә... Дәрдемәнд эзләре буйлап озын сәфәргә чыгып киткән Лирон Хәмидуллин. Хәзерге Башкортстан белән Чиләбе өлкәсенә кергән кала-салаларда олырак буын вәкилләреннән Рәмиевләргә кагылышлы истәлекләр язып ала. Фотосурәтләр дә туплана. Уфа һәм Оренбург архивларында казгану көтелгәннән дә яхшырак нәтиҗәләр бирә... Аның “Офыктагы рәшәләр” исемле калын китабы менә шундый җентекле өйрәнү нәтиҗәсендә туа... “Дәрдемәнд” дип исемләнгән үзенчәлекле фотоальбом, рус телендә “Дэрдменд”, “Поэт, издатель, меценат” дигән китаплар дөнья күрә. Лирон Хәмидуллин “Бертуган Рәмиевләр” басмасын әзерләүдә дә турыдан-туры катнаша... Татар халкының затлы улы Дәрдемәнднең биографиясен гыйльми торгызуда Лирон Хәмидуллиннан да зуррак өлеш кертүче тагын бармы?

... Йөргән аякка йөрем иярә. Югарыда беркадәр гөман кылып әйтелгәннәргә чираттагы дәлил рәвешендә “Галиябану туган якларда” исемле хезмәт укучы хөкеменә тапшырыла. Лирон Хәмидуллинның башка мәкаләләрендә дә мәшһүр драматург Мирхәйдәр Фәйзинең әдәби-гыйльми портретына өстәмә шәрехләрне очратырга мөмкин.

...Хәйран калырлык, Лирон Хәмидуллинның Оренбург өлкәсендәге Каргалы бистәсендә тикшеренүләр алып баруы нәтиҗәсендә Габдерәхим Утыз Имәнинең тормышына бәйле мәгълүматлар табыла ...Бактың исә, Габдерәхим Утыз Имәнине укыткан мөдәррисләр Салават Юлаевка да белем биргән. Шушы ук бистәдә дөньяга килгән Әбелмәних Каргалый... -шагыйрь Габдессәлам ибн Ураиның оныгы икән бит. Соңгысы Каргалы мәдрәсәсенең химаячесе һәм ахун булган, милли каһарманыбыз Батырша белән якын бәйләнештә торган. Менә нинди атаклы бистә, язмыш юллары кисешкән урын! Монда Салават белән Батырша дини белем генә алмаган, йөрәкләрендә менә-менә дөрләп китәр гыйсъянчылык утын да йөрткән. Шагыйрь Һибәтулла Салихов та Каргалы мәдрәсәсендә укып, соңыннан биредә өлкән укытучы дәрәҗәсенә кадәр



күтәрелгән. Боларның бөтенесе турында тәфсилле мәгълүматны Лирон Хәмидуллин эзләнүләрендә табарга мөмкин...

Алга карап фикер йөртә белгән тикшеренүче әдипләр турында гына түгел, бүтән зыялы затларыбыз хакында да материал туплауны максат итеп куйган. Татарның концертлар биргән тәүге музыкантларыннан берсе Фәйзулла Туишев аның ихлас кайгыртулы игътибарыннан ничек читтә калсын инде?! Дан казанган әлеге гармунчы – Лирон Хәмидуллинның авылдашы бит...

Сәясәтче һәм җәмәгать эшлеклесе Йосыф Акчураның портреты Лирон Хәмидуллинның төпченүле хезмәтеннән башка тулы булмас иде. Тарих галиме, филолог, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе Габделбари Баттал да, журналист, нашир, җырчы һәм көйләр авторы Камил Мотыйгый да, җәмәгать эшлеклесе, педагог һәм публицист Шакир Мөхәммәдъяров та Лирон Хәмидуллин тикшеренмәләрендә өстәмә шәрехләү тапты...

Әйтергә кирәк, Лирон Хәмидуллинның улы яшь тарихчы Булат Хәмидуллин Татарстанның фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт премиясенә лаек булды... Димәк, сайланган юлның өзелмәве варислар казанышында раслана. Аталы-уллы Хәмидуллиннарның уртак китаплар бастыруы да шул нәтиҗәле дәвамчанлыкны ачык итеп күрсәтә... Хәмидуллиннар гаиләсендә кызлары Зөһрә дә үз эти-әнисенә бик лаек...

Гаделлек саклап әйткәндә, бу гаиләдәге тәрбиянең уңышлы куелышында Дания ханымның өлеше аеруча зур... Әлбәттә, әдипнең таянычы булу җиңел генә бирелми. Мондый миссия өчен дә зур талант көче кирәк. Әзерлек тә сорала. Күпләр шаһит, Дания Ибраһим кызы озак еллар Язучылар берлеге карамагындагы оешмаларда эшләде, каләм ияләренең эчке тормышындагы хәлләр белән һәрдаим хәбәрдар булырга тырышты. Яңа әдәби әсәрләрне укып баруы да аның зыялы зат икәнлеген раслап тора. Язучы хатыннарының классик үрнәге. Һәрьяклап уңган Дания ханымны әнә шулай бәяләргә мөмкин.

...Күпне белгән юламаннар ярдәме максатка ирешүне мотлак җиңеләйтә. Шушы уңайдан академик Миркасыйм Госмановның сүзләре хәтердә яңара: “Ул һәр очрашкан саен сине кысыграк күзләрен тагын да кыса төшеп, күзлеген төзәтә-төзәтә, якты чырай белән елмаеп каршылар. Карашында аның “Кирәгем булса – әзермен...” дигән кебегрәк сораулы чалым да чагыла сыман”.

Ышанып әйтергә мөмкин, Лирон Хәмидуллинның әзер торуы беркемдә дә шик уятмыйдыр. Ул галимнәргә дә, үзенең каләмдәшләренә дә, укучыларына да кирәк. Аның булышлык күрсәтергә ашкынуы халкыбыз өчен бик мөһим.

***ЗиннурМансуров, шагыйрь,***
***ГабдуллаТукай премиясе лауреаты***

## МОҢЛЫ ЯДКАРЬ

*(Мәшһүр әдип Рабит Батуллага)*

Күптән инде, күптән очрашкан юк...
Җыя иде безне Батулла...
Ул көннәрдән бары ядкарь калды, –
Үткәннәргә юл юк кайтырга.

Күптән инде, бергә дулаган юк,
Кабынган юк, дөрләп янган юк.
Үз илеңдә үзең хуҗа булып,
Мәйданнарда батыр калган юк.

Күптән инде, күптән елаган юк.
Зиратларда яшьләр сыккан юк.
Йодрык төйнәп, нәфрәт сүзе сөйләп
Урамнарга ярсып чыккан юк.

Күптән инде, күптән адашкан юк,
Гөнаһ кылган, азган-тузган юк.
Черек күлнең шомлы бакчасыннан
“Карурман”ны җырлап узган юк.

Күптән инде, күптән дуслар белән
Җыелган юк, корбан чалган юк.
Әйтерсең лә иманыбыз камил,
Әйтерсең лә җирдә ялган юк.

Күптән инде, күптән Обком да юк,
Дәүләт тә юк, көткән ил дә юк.
Ядкарь булып калды татлы хыял,
Узды еллар сорап, теләнеп.

Күптән инде, күптән, ирек даулап,
Чатырларга байрак элгән юк.
Тукай әйткән: татар йоклагандыр...
Уянырмы берчак? Белгән юк...

Күптән инде, күптән очрашкан юк...
Үткәннәргә кире кайту юк.
Хыяллардан корган дәүләтемдә
Батулла бар, әмма Бату юк!

***Разил Вәлиев,***
***Татарстанның халык шагыйре***

***Фикер № 2, 2018 ел***



**Татарстанның халык язучысы**
**РАБИТ МӨХЛИС УЛЫ**
**БАТУЛЛАГА**
**80 ЯШЬ**

## ДРУГУ 80 ЛЕТ

С Робертом Батуллиным меня познакомил Ильгам Шакиров. Случилось это в конце 1969 года на вечере творческой молодежи, организованном Батуллой в Доме актеров в Казани. В Казань я заехал на недельку по пути домой после поездки в Зеленодольский завод холодильников, с которым сотрудничал Казахский политехнический институт г.Алма-Ата, где я тогда работал.

Таким образом у меня появилась возможность в течение последующих двух с лишним лет бывать в Казани в желаемое время, совмещая полезное с приятным. В каждый свой приезд в Казань я оказывался в гуще событий: праздники, концерты, театральные премьеры... Почти на всех мероприятиях я бывал вместе с Батуллой, нередко еще и с Ильгамом Шакировым. Праздники я проводил в компании друзей Батуллы, побывал вместе с ним на дачах писателей на Лебяжьих озерах. Так мне посчастливилось познакомиться с легендарными личностями: Хасаном ага Туфаном, Накый ага Исанбатом. Перекинуться парой фраз с каждым из них было событием для многих. Я, конечно, понимал, что сам я интересен им как иностранец – потомок эмигрировавших в Китай земляков. Через Батуллу я познакомился в те же годы с артистами театра Камала, с молодыми поэтами и писателями. Со многими из них продолжаю общаться по сей день, поддерживаю дружеские отношения.

Батулла воочию старался показать мне как живут татары в Татарстане с первых дней нашего знакомства. Он стал моим

гидом при ознакомлении с Казанью, возил меня по Татарстану. В 1971 году мы с ним побывали на сабантуе в ауле Ташлык у Разиля Валеева. В 1980 г. в дни республиканского сабантуя в Челнах он провез меня на своей машине по близлежащим татарским аулам и русским деревням, чтобы я мог сравнить их. В одной из деревень под предлогом «попить водицы» завел меня в дом русской семьи. У татар мы всегда оказывались желанными гостями (хоть и незваными). Все сравнения, конечно, оказывались не в пользу русских.

В связи с этим вспоминается одна авторская передача корреспондента радиостанции *BBC* Фатимы Салказановой «От Калининграда до Владивостока». Значительная часть передачи была посвящена жизни и быту татар. Она восхищается трудолюбием и чистоплотностью татар, ухоженностью и добротностью их дворов и домов повсюду, где она побывала, и говорит: «Мы на Западе называем татар русскими баварцами».

Мы не раз бывали вместе в Булгаре еще до начала реставрационных работ и после. В 2015 году по приглашению Рабита я побывал вместе с И.Шакировым и группой творческой интеллигенции в Ак мечети, построенной на священной земле Булгар.

Я достаточно часто встречался и общался с Р.Батуллой, бывал в его коммунальной квартире на Чеховской, в одной из комнат которой ютилась семья Батуллиных. Случалось оставаться там ночевать. Благодаря этому я был в курсе частной и семейной жизни Батуллы: знал о «приглашениях» в обком партии на собеседования, о проблемах с публикацией статей и рассказов в СМИ, изданием книг. Какое-то время у него были проблемы и с работой. Все это было связано с его профессией. Рассказы и сказки с критикой строя и правителей советского периода (рассказ «Печать», сказка «На скотном дворе» и т.п.), написаны им не из-за «безбашенности» (Р.Б.), конечно. Только истинный патриот, уверенный в своей правоте, небезразличный к судьбе своего народа, нетерпимый к несправедливостям, творимым с народом, мог позволить себе становиться «безбашенным» в те сложные времена. Верный себе Р.Б. с юмором и даже сарказмом пережил их – эти сложные времена. Шуточные рассказы друзьям-знакомым об отоваривании в буфете обкома дефицитом – чем не повод для создания новых проблем для себя? Истинным патриотизмом я объясняю его искреннее внимание к гостям (даже неофициальным) своей страны: ему небезразлично, как патриоту, с какими впечатлениями и мнением о хозяевах покинет страну гость, кто бы он ни был.

В августе 2002 года я обратился к Батулле с вопросом о возможности бесплатного обучения татарской молодежи из Китая в вузах Казани. После нашей совместной беседы с депутатом Госсовета Татарстана Разилем Валеевым было решено, что для переговоров по этому вопросу должен приехать представитель татарского общества из Китая. Организацию встречи с президентом взял на себя Разиль Валеев. Встреча делегации татарского общества во главе с Ильяром Габитовым из г.Кульджа (КНР) с президентом Татарстана М.Ш. Шаймиевым состоялась в первый же после отпуска рабочий день президента в январе 2003 года. Неофициальным представителем китайских татар на этой встрече выступил и Р.Батулла. Вопрос был решен положительно. На той же встрече Р.Батулла обратился к Президенту с предложением открыть в Казани музей татар-эмигрантов. И вот, наконец, в 2017 году было принято решение об осуществлении этого проекта.

Первая партия (группа) татарской молодежи из Китая приступила к учебе в Казани в сентябре 2005 года – в год тысячелетия г.Казань.Опеку над ними взяли на себя ныне покойный академик Миркасыйм Усманов и руководство ВКТ. Опорой растерявшейся в незнакомой среде части молодежи стали семьи Батуллиных и Муслимовых.

Я благодарен судьбе, что в нужное время пересеклись наши с Рабитом Батуллой жизненные пути, счастлив, что благодаря этому мы стали друзьями. Роберт Батуллин уже давно стал Рабитом Батуллой. Рабит – в переводе с арабского «связывающий, соединяющий». Сохранив ***связи*** со своими предками через знание истории своего народа, через воспитание будущих поколений на традиционных национальных обычаях и традициях мы сохранимся на этой земле как народ (нация). Рабит Батулла был и останется учителем-воспитателем через свое творчество и на примере своей жизни и своей семьи способствующим этому.

*Мөхтәрәм һәм кадерле җан дустым Рабит!*

*Олуг тормыш бәйрәмең мөбәрәк булсын! Сиңа, хатының Рузияга газиз әниемнең сүзләре аша шат һәм бәхетле тормыш теләп калам. Варисларыңның бәхетле тормышын, уңышларын күзәтеп, шатланып яшәргә насыйп булсын. Амин!*

***Рабин Сафаргали, Алматы***

## КОТЛЫЙБЫЗ!






***Казакъстан татарлары һәм башкортлары Конгрессының рәисе***

***ТӘҮФИКЪ АКРАМ улы***

***КӘРИМОВКА***

***60 яшь***



***Алматы өлкәсе татар һәм башкорт мәдәнияте җәмгыятенең Узунагаш филиалы рәисе***

***ИЛДАР АБРАР улы***
***ЮЛДАБАЕВКА 60 яшь***



***Казакъстан татарлары һәм башкортлары Конгрессы рәисенең урынбасары***

***РИНАТ АБУЛХАН улы***
***АБДУЛХАЛИКОВКА 50 яшь***

## МАРСЕЛЬ ЗАКИР УЛЫ КИЛДИЯРОВ ИСТӘЛЕГЕНӘ



***Марсель Закир улы Килдияров*** *(1949-2017)- техник фәннәр кандидаты, отставкадагы полковник, Әфганстандагы сугышларда катнашкан. Алматы каласында үткәрелгән татар-башкорт милли мәдәни чараларда актив катнашучы, «Умырзая» исемендәге җыр ансамблен оештыручы һәм аның җитәкчесе. Башкортостанда туып үскән. Уфа нефть институтын, Караганда милиция мәктәбен һәм партия югары мәктәбен тәмамлаган. Орденнар һәм медальләр белән бүләкләнгән.*

## ТАТАР МОҢЫ ҮЛМӘС ӘЛЕ

*70 яшен дә тутырмыйча арабыздан вакытсыз мәңгелек йортына киткән нечкә күңелле оста гармунчы, моңдаш дустым, якташым Марсель Закир улының якты рухына багышлыйм*

Сентябрьнең уникесендә
Кара төнне караңгылатып,
Марсель вафат булган, - дигән
Үзәк өзгеч хәбәр таралды.

Кайгы болыты каплады
Татар дөньясының күген.
Мәңгелек йортына озаттык
Марсель дустымны бүген.

Мәңгелеккә саубуллашып,
Китеп барды безнең арадан.
Моңлы гармун ятим калды,
Йөрәк әрни тирән ярадан.

Исән чакта чын күңелдән
Эшләде ул күпме яхшылык.
Тыныч кына ята хәзер,
Ә йөзендә серле яктылык.

Ә бит сиңа әле тагын
Яшәргә дә иде, яшәргә!
Җан дусларын моңга төреп,
Гармун теле белән дәшәргә!

Кулларында гармун булды,
Уйнаганда күңеле тулды.
Милләтем дип җан атканга
Эшләгән эшләре уңды.

Марсель дустым, син күптәннән
Халкымның горурлыгы идең!
Милләтпәрвәр моңсар булдың,
Һәрвакыт сабыр, тыйнак идең,
Татарым дип янып-көйдең.
Исән чакта рәхмәт әйтәлмәдек,
Марсель дустым, сыйпап башыңнан.

Үзең китсәң, моңың калды!
Йөрәкләрдә урын алды.
Әйтер сүзләрең булгандыр-
Күңелләрдә калды үкенеч,
Ишетмәдек соңгы сүзеңне...
Син калырган моңга моңланып,
Онытмабыз мәңге үзеңне!

***Равил Гозәиров, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы***

***Фикер № 2, 2018 ел***

**ПАМЯТИ**
**МАРСЕЛЯ ЗАКИРОВИЧА**

Марсель Закирович Кильдияров организовал ансамбль татарской песни «Умырзая» в 2008 году и был бессменным его руководителем. Это был очень музыкальный, влюбенный в татарскую песню и сам поющий человек, отлично владеющий родным татарским языком. Он виртуозно играл на гармони, играл на баяне, пианино и т.д.

Впервые я встретилась с ним в 2008 году, просто пришла к нему на работу. И мы начали петь и выступать. Еженедельно после работы он безотказно играл нам, и мы пели песни на нашем родном языке. Был создан ансамбль, в первый состав которого вошли Маркина Фагиля, Мамбетжанова Филиза, Гайсина Зайтуна, Сабитова Альфия и я- Хусаинова Рашида. Фагиля стала нашим музыкальным редактором, за ней- новые песни, диски, кассеты, печать, фотографии. Я - староста ансамбля, за мной -административные дела, оповещение, сбор и т.п.

Мы собирались по субботам, разучивали очень много песен под аккомпанемент Марселя Закировича. Он был бескорыстным человеком, пожалуй, единственным бескорыстным гармонистом в Казахстане. Он играл повсюду, куда его приглашали.

Сколько песен мы изучили под его руководством- шесть альбомов с рукописными и печатными листами! Мы душевно общались, много смеялись, отмечали дни рождения. Это самые приятные воспоминания. Я надеюсь, что Марсель Закирович тоже отдыхал душой, он вспоминал свои родные края- Башкортостан со слезами и улыбкой.

В будние дни он общался со всеми нами по телефону. При этом он спрашивал нас, а что это за песня, кто ее авторы, кто из артистов ее исполняет и т.д. Он поправлял наши ошибки в татарской речи, добивался точного выражения мелодии и смысла татарских песен. Марсель Закирович был очень скромным, он никогда не выпячивал себя.

Он неустанно музифицировал; мне, да и всем нам нравились его аранжировки татарских песен. Сколько редких и старинных песен мы разучили с ним, он их переписывал с кассет и дисков, вдохновлял нас.

А наши чаепития! Сколько мы смеялись и шутили, сколько радости мы получали от общения с этим незабываемым человеком. Под руководством Марселя Закировича мы пели и плясали, выступали на телевидении, на сабантуях и других народных праздниках, везде, куда нас приглашали.

Года два тому назад ансамбль наш обновился, появились замечательные певицы Хасанова Махмуна, Хусаинова Хания, Саметова Рашида, Султанова Роза, Баймурзина Марьямбике, Фазылова Галиба, Хасанбакиева Таслима. Позже к нам присоединились Узбекова Альфия, Исхакова Афарида, Ахмерова Сания. Давно поет с нами Галиева Сания, она сама прекрасная солистка и играет на баяне. В ансамбле у нас чудесные люди, спасибо им всем!

Нам оказывают большую помощь известные активисты татарских культурных центров. Благодаря Рашиду Рахматулловичу Гизатуллину мы пользуемся прекрасным залом с чудесной акустикой для наших репетиций. Постоянную поддержку ансамблю оказывает Виктория Шарипова. С нами занимается Равиль Гузаиров- настоящий поэт, писатель, певец. На концертах нам аккомпанирует Галимжан Тамендаров- очень талантливый баянист. Мы им всем очень благодарны!

Однако в настоящее время ансамбль «Умырзая» переживает очень трудный период. Мы понесли невосполнимую утрату, мы осиротели. У нас нет теперь постоянного баяниста-профессионала. Марсель Закирович оказался незаменимым, это был настоящий подвижник татарской музыки. Мы все искренне любили этого прекрасного человека, человека большой души. Ушел от нас талантливейший человек, мы никогда не забудем его.

В заключение я хотела бы поблагодарить вдову Марселя Закировича Валентину Александровну, которая оказала возможную поддержку при сборе материалов о нашем дорогом руководителе.

***Рашида Хусаинова***


16 06 2013


Сабантуй
2009

**БУЛГАННЫҢ КАДЕРЕН БЕЛМИБЕЗ ШУЛ...**

Чынлап та, барны, булганны кадерли дә, саклый да белмибез бит. Бу сүзләр үткәннәрне искә төшерә. Без барыбыз да үзебез теләгән вакытта- эш вакытында булсын, ял вакытында булсын- Марсель Закировичның мастерскоена килә идек. Монда үзара аралашу, хәлләр белешү, эчтәге серләрең белән бүлешү, кирәгендә киңәшләшү дә була иде. Хәзер генә шуны аңладык бит: шушы тыйнак, ачык кеше белән аралашу үзе зур бәхет булган икән...

2008 елда Марсель Закирович татар җырын сөюче берничә кешене чәй эчеп, сөйләшеп, гармунга кушылып җырлашып утырырга чакырды. Менә без- Фәгыйлә Маркина, Әлфия Сабитова һәм мин- Филизә Мамбетжанова (Әминева)- Марсель Закировичның мастерскоенда җыелдык. Рәшидә Хөсәенова бездән дә алдарак монда «юл салган» икән. Шулай итеп, без башта дүртәүләп, соңрак бүтәннәр дә кушылып, монда очраша башладык.

Без җомга көне яисә ял көннәрендә җыела идек. Шушы кичәләргә һәркем тәмле татар ашамлыкларын алып килә. Барыбыз бергә утырып, кыстыбый, коймак, вак бәлеш, зур бәлеш, бәрәңгеле каз ите һәм башка ашамлыклар белән сыйланабыз.

Чын дусларча шартларда Марсельнең мастерскоенда безнең кичәләр үтә иде, татар җыр культурасын өйрәнү һәм аңа кушылу кичәләре. Ә Марсельдә тулы бер фонотека, яшь чагыннан ук җыя башлаган җырлар бар икән. Шунда ук, мастерскойда, Марсельнең үзенең әллә күпме музыкаль инструментлары - баяннар, гармуннар, япон ионикасы, трубалар һәм башкалар саклана иде.

Марсель Башкортостанның, Татарстанның бик күп җырчыларын, аларның җырларын, репертуарларын да белә икән. Алма-Атада киң танылган «Сарман» ансамблен дә ул еш кына искә ала иде. Музыкаль җитәкче Халит Закировичны, җырчылар Нәкыя, Фирдәүс, Заһитларны, гармунчы Әхтәм абыйны һәм башкаларны хөрмәт белән, яратып искә ала иде. «Сарман» ансамбленең әгъзалары - җырчылар Гозәиров Рәвилнең, Сайбулатова Галибәнең, баянчылар Тамендаров Галимҗанның, Шакиров Рунарның һәм башкаларның талантларына соклана иде.

«Умырзая» ансамбленең беренче составы- рус мәктәпләрен тәмамлаган, һәм рус культурасында үскән кешеләр булып чыкты. Карасаң, без беребез дә татар җырларын юньләп белмибез икән. Марсель Закирович безгә татар җырларының гүзәллеген аңлатырга, шуларны яратып җырларгы өйрәтергә тырышты. Нинди дә булса җырны өйрәнә башлаганда Марсель үзенең матур тембрлы тавышы белән, татарларга гына хас булган моң белән җырлап күрсәтә иде. Җырга Рәшидә кушыла иде, музыкаль грамотаны белгән Фәгыйлә күтәреп ала. Аннары - Әлфия үзенең матур тавышы белән, ин соңында –мин.

Марсель Закирович кушуы буенча без барыбыз да файллы папкалар сатып алдык, шул папкаларга яңа җырлар кушыла башлады. Фәгыйлә интернеттан җырларның текстларын табып алып, барыбызга да бастырып алып килә торган булды. Марсель Закирович яңа матур җырны ишетеп калса, аны компьютерга язып ала да, үзе өйрәнә, аннары безгә өйрәтә иде.

Соңрак безгә Зәйтүнә Гайсина килеп кушылды. Зәйтүнәнең тавышы бик чиста, матур, көмеш тавышсыман, үзе аккордеонда да уйнап җибәрә. Тора-бара Марсель янында бер группа оешты, Марсельнең тәкъдиме белән аны «Умырзая» ансамбле дип атадык. Рәшидә Саметова, Хәния Хөсәенова, Мәрьямбикә Баймурзина, Мәэмүнә Хәсәнова, Галибә Фазылова, Роза Султанова һәм башкалар кушылдылар. Безнең ансамбль Алматыда сабантуйларда, татар үзәкләренең чараларында күп кенә чыгышлар ясады. Уйласам, шул вакытлар безнең өчен бик бәхетле вакытлар булган икән. Ансамбльдә йөрүчеләр нигездә пенсиядәге хатын-кызлар, менә шул очрашулар, җырлашулар безгә шатлыклы көннәр алып килде, гомеребезне тулыландырып торды. Хәзерге көндә ансамбль ятим, безнең хөрмәтле һәм сөекле җитәкчебез Марсель юк...

Гаилә башлыгы, ата һәм бабай булган Марсель башка кешеләр белән ачык, гади, үзара аралашуга әзер иде. Ләкин үзе турында ачылып китә торган кеше түгел иде. Бу аның профессиональ тормышына бәйле. Ул бит разведка полковнигы, Афганстандагы сугышларда катнашкан кеше. Мастерскойдагы үзенең төп эше белән бергә ул элеккеге хәрби дуслары белән очрашып, аралашып тора иде. Аның наградалары бик күп иде- рәхмәт хатлары, грамоталар, медальләр, орденнар. Аның шул кадәр бүләкләрен күреп, без таң калган идек. Аннары аны барыбыз да котлап, бу хәтле бүләкләрен сер итеп саклаганы өчен үзенә шелтә дә ясадык. Ул елмайды гына, бик тыйнак кеше иде шул Марсель Кильдияров.

Менә шундый булып Марсель Закир улы Кильдияров безнең хәтердә мәңге сакланыр: тыйнак, эчкерсез, кешеләргә ачык, туган татар халкын, гүзәл татар телен чын күңелдән сөя белгән, кабатланмаслык кеше.

***Филизә Мамбетжанова (Әминева)***


Сабантуй
Сабантуй



***Казакъстан татарлары һәм башкортлаы конгрессының оешмаларында***
***Муса Җәлилгә багышланган кичәләр уздырылды.***

**Семей шәһәрендә үткән кичә**

## ЖИЗНЬ МОЯ БЫЛА ОДНОЙ ПЕСНЕЙ

14 февраля в Центральной библиотеке г. Семея прошел музыкально-литературный вечер, посвященный великому татарскому поэту, Герою Советского Союза, лауреату Ленинской премии Мусе Джалилю. Организаторами мероприятия выступила Ассоциация «Прииртышский союз татар и башкир «Хак» в лице Татарской школы искусств, Молодежного общественного объединения «Детско-юношеская организация «Мирас» и народных ансамблей «Истәлек» и «Иртыш моңнары». В вечере вспомнили жизнь и творчество поэта, представили видео- и аудио-фрагменты из воспоминаний родных, близких и тех, кто изучал его жизнь и творчество. Небольшие инсценировки придали мероприятию особую атмосферу того времени. В завершении вечера не смог не поделиться впечатлениями ветеран ВОВ Габдулгазиз Ахмеров. Он пожелал всем мира и согласия.

## ГОМЕРЕМ МИНЕМ МОҢЛЫ БЕР ҖЫР ИДЕ

Дөнья әдәбияты тарихында иҗатлары белән исемнәрен мәңгелек данга күмгән күп шагыйрьләр бар. Ләкин, каһарман шагыйрь Муса Җәлил кебек, әсәрләре белән дә, үлеме белән дә исемен мәңгеләштергән шагыйрьләр аз. Февраль ае халкыбызга Муса Җәлилне биргән ай. Халкыбыз аның туган көнен билгеләп үтә. 14 февраль көнне Семей шәһәренең Үзәк китапханәсендә дә каһарман шагыйрь Муса Җәлил иҗатына багышланган "Гомрем минем моңлы бер җыр иде" исемләнгән әдәби-музыкаль кичә булып узды. Кичәне «Хак» Иртыш буе татарлар һәм башкортлар берләшмәсе» Ассоциациясе кармагындагы Татар сәнгать мәктәбе укучылары, укытучылары, «Истәлек» татар халык фольклор-этнографик ансамбле, «Иртыш моңнары» халык җыр ансамбле, «Мирас» татар яшьләре оешмасы катнашты. Кичә барышында оештыручылар Муса Җәлилнең тормышын, иҗатын, аның уңышларын, шул ук вакытта үз гомерендә кичергәннәрен тамашачы күңеленә җиткерергә тырыштылар. Шагыйрь турында туганнарның, дусларның, аның тормышын, иҗатын өйрәнгән шәхесләрнең истәлекләрен күрсәтү, тыңлату, шулай ук кичәдә сәхнәләштерелгән композицияләр күрсәтү чараны тагын да тәэсирлерәк итте. Китапханә хезмәткәрләре шагыйрьгә бәйле күргәзмә тәкъдим иттеләр. Кичәдән соң тамашачылар Муса Җәлил тормышына һәм гомумән бу чарага карата үз фикерләрен белдерделәр. Бөек Ватан сугышы ветераны, Австрия, Венгрия, Чехословакия илләрен азат итүдә катнашкан Габделгазиз Әхмәров кичәдән бик канәгать калды, барыбызга да тынычлык, татулык теләде.

Мондый чараларның кирәклегендә шик юк, әлбәттә. Шунысы игътибарга лаек: тамашачылар арасында төрле яшь һәм төрле милләт вәкилләре булды. Димәк, шагыйрьнең иҗаты татарлар өчен генә түгел, ә башка халыклар өчен дә якын.

Һәр мизгел тарихи истәлеккә теркәлде. Әдип татар әдәбиятына көчле әсәрләр генә түгел, ә үзеннән соң милләт өчен хезмәт итүче алмаш тәрбияләгән шәхес. Муса Җәлил батырлыгы һәрбер кеше йөрәгендә мәңге сакланачак!

***Ахунҗанова Диләнур, Семей шәһәре***





## *Кокшетау шәһәрендә үткән кичә күренешләре*

## Что имени тебе в моем…

Новый 2018 год привнес в жизнь кокшетауских татар немало новых хлопот и испытаний на прочность и верность избранному пути. А это конечно же, пропаганда и сохранение родного языка и культуры. Об этом неоднократно шел разговор на собраниях актива общественного объединения татар и башкир Акмолинской области.

Что ж, сделано в прошедшем немало. И это значимо. Проведены традиционные национальные праздники Сабантуй и Чак-чак байрям. Состоялись поездки на республиканский праздник в Костанай, концертные выступления в городах и поселках с компактным проживанием татарского населения – Степногорске, Имантау. Удачным можно назвать выступление маленькой «звездочки» воскресной школы Суфии Усмановой на региональном конкурсе «Мисс татарочка». Своеобразным итогом творческой работы журналиста Ларисы Аитовой стал выход в свет очередной книги «Родительский дом», посвященной истории татар.

Новый 2018-й открылся конечно же, елкой для детей и взрослых татар, проживающих в Кокшетау. Пели, водили хороводы, получали презенты, пили чай за дастарханом со своей национальной выпечкой.

А в середине февраля проведен День памяти Мусы Джалиля, который теперь планируется установить традиционным. Имя выдающегося поэта-героя не должна подвергнуться забвению. В программе, разработанной преподавателем школы «Шанырак» Гаухар Аминовой, пожалуй, были учтены все моменты судьбы и творчества великого представителя татарского народа. Активисты этнообъединения читали стихи, рассказывали о значимых событиях из жизни Героя. Солисты фольклорного ансамбля «Галиябану» исполнили песни – о любви к Родине, матери, солдатском подвиге в годы войны. Все сказанные слова и мелодии были проникнуты патриотическим пафосом за Поэта Мира, чьи произведения достойно вошли в золотую коллекцию бесценного достояния татарского народа.

В выступлении председателя Центра Рафаила Сулькарнаева поднимались и нерешенные проблемы, которые не осилить без поддержки местной власти. Почти два года стоит готовый памятник Мусе Джалилю, изготовленный по инициативе местного предпринимателя Эльдара Азизова. Собирались и народные средства на постамент под уже готовый бюст. Тем не менее вопрос этот стал неразрешимым из-за выделения места в центре Кокшетау. Даже возникают разговоры о том, что Герой не имеет никакого отношения к Казахстану и к областному центру. Мыслимое ли дело! Ведь в годы Великой Отечественной никто не спрашивал кто и какой национальности и откуда призывался на защиту Отечества! Да и в составе легиона татар и башкир «Идель-Урал» три казахстанца. Один из них, Ахат Аднашев, уроженец Петропавловска, а призывался на фронт из близлежащего городка Степняка…

Второй проблемой и тоже значимой для нашей диаспоры называлось набившее оскомину торможение с присвоением звания «народный» татарскому фольклорному ансамблю «Галиябану». А ведь уже в следующем году коллективу исполнится 30 лет!

Так что планов у кокшетауских татар хватает. Юбилеи активистов, поездки с гастролями… Хватило бы сил реализовать их в конкретные дела.

***Лариса Хабибулина (Аитова), Кокшетау***


Муса Джалиль
поэт - герой


Принят на XXIV сессии
Ассамблеи народа Казахстана
26 апреля 2016 года.


Қазақстанның болашағы
біздің қолымызда!
Будущее Казахстана
в наших руках!

***Уральски шәһәрендә үткән кичә күренешләре***










## *Атырау шәһәрендә үткән кичә күренешләре*








## ЦЕНТР “ИЛЬДАШ”

Татарский центр гуманитарного развития «Ильдаш» был зарегистрирован в 1995 году. Основателем и первым председателем центра являлся Исмагил Лутфуллович Шарипов. С 2012 года центр возглавляет Ниязова Нурия- член Ассамблеи народа Казахстана, председатель Совета матерей при АНК г. Алматы, депутат маслихата г. Алматы.

Одна из самых важных задач центра –забота о полноценном функционировании мечети «Фатима», возрожденной на своем историческом месте в Татарской слободе в 2003 году. «Ильдаш» оказывает всестороннюю хозяйственно-финансовую поддержку в функционировании мечети: оснащает ее необходимым инвентарем, облагораживает территорию, строит детские спортивные площадки. Центр тесно сотрудничает с Духовным управлением мусульман Казахстана и имамом мечети «Фатима», участвует в организации мероприятия «Ауызашар» и т.п.

Забота о подрастающем поколении – первоочередная миссия центра «Ильдаш». С этой целью на территории мечети «Фатима» действуют летние курсы обучения детей от 6 до 15 лет, сюда приезжают каждое лето до 50 детей, из малообеспеченных семей (из разных регионов Казахстана). Здесь ежегодно проводится благотворительная акция «Путь к школе». К началу нового учебного года дети из малоимущих семей района Татарки, а также участники летних курсов получают подарки-



школьные ранцы со всеми необходимыми принадлежностями.

Центр проводит немало благотворительных мероприятий. В частности:

- была произведена посадка аллеи, очищена территория от мусора, создана и облагорожена детская площадка, благоустроена территория мечети «Фатима»;
- проводятся праздничные мероприятия и благотворительные детские утренники;
-подготовлен и согласован меморандум с лицеем «Арыстан» и Советом матерей при АНК г.Алматы для принятия в Специализированный лицей юношей и подростков из неблагополучных семей и детских домов;
-оказывается шефская поддержка пациентам Научного центра педиатрии и детской хирургии; проводится акция «От детской улыбки в мире всем светлей»;
-под личную опеку Ниязовой Нурии был взят Приют временного содержания несовершеннолетних г. Алматы; здесь регулярно проводятся праздники, оказывается материальная и медицинская помощь и т.п.; осуществляется юридическая и правовая поддержка;

- проведены акции «Соберем ребенка в школу» для детей из малообеспеченных и многодетных семей и для детей – сирот;
-проведены благотворительные мероприятия для детей с ограниченными возможностями, а также для детей, больных эпилепсией и т.д.

В соответствии с планом работы Центра 2018 год будет не менее насыщенным.

В частности, планируется проведение праздничных мероприятий и благотворительных акций, субботников, встреч и круглых столов по насущным проблемам гуманитарного развития; проведение викторины «Что? Где? Когда?» совместно с этнокультурными объединениями г. Алматы, направленной на изучение культуры и обычаев народов страны; продолжение работы по поддержке Центра адаптации несовершеннолетних детей и т.д.

Татарский центр «Ильдаш» всегда работал и работает на благо процветания нашего Дома, а наш ДОМ – ЭТО КАЗАХСТАН. В доме всегда должно быть чисто, уютно, сытно и, самое главное – ДРУЖНО. Для этого очень важно не быть равнодушным, а, значит,




много работать. Работать на благо и во благо. Потому что в этом доме живем мы, рождаются наши дети и будут рождаться внуки. И как мы их научим, так они и будут жить в нашем доме. А учить мы обязаны свои примером, всем сердцем и, что очень важно, с любовью.

***Нурия Ниязова, Алматы***



**ХИСАП ҖЫЕЛЫШЫ**

Уральски шәһәрендә Көнбатыш Казакъстан өлкәсе татар милли- мәдәни үзәгенең хисап җыелышы үткәрелде. Үзәк идарәсенең һәм үзәк рәисе Флүрә Ириковна Миликееваның эшенә җыелышта катнашучылар югары бәя бирделәр.





## Руководителям татарских национально-культурных центров в России и зарубежных странах

***О поступлении в вузы Республики Татарстан на целевой основе в 2018 г.***

Исполком Всемирного конгресса татар, Министерство образования и науки РТ в соответствии с поручением Президента Республики Татарстан Минниханова Р.Н. и приказом Министерства образования и науки РФ № 844 от 28.07.2014 г. продолжает работу по содействию в поступлении на целевой основе граждан России, иностранных граждан из числа татарских соотечественников, проживающих в странах СНГ и дальнем зарубежье, в высшие учебные заведения Российской Федерации, расположенные на территории Республики Татарстан. С этой целью приемными комиссиями татарстанских вузов будут организованы выезды в эти страны для проведения тестов и экзаменов.

Просим руководителей в срок до 15 мая с.г. заполнить анкеты абитуриентов на сайте Всемирного конгресса татар. По мере готовности направить в адрес Исполкома Всемирного конгресса татар на е-майл: radikl@live.ru копии документов об образовании, паспортов абитуриентов, а также утвержденных двусторонних договоров о целевом обучении с организациями заказчиками. Оригиналы документов представляются в вузы непосредственно абитуриентами.

В текущем году Исполкомом ВКТ заявки на целевое обучение в вузах Татарстана по медицинским, экономическим, юридическим специальностям приниматься не будут. Также рассмотрению не подлежат обращения в случае полученных оценок ЕГЭ по профильным предметам ниже 65 баллов.

Более полная информация о предъявляемых требованиях к абитуриентам находится на официальных сайтах вузов.

Для справок обращаться: Муллагалиев Радик Гаделович, моб. телефон: 89874218343, e-mail: radikl@live.ru.

---

***Дорогие читатели газеты!***

***Ваши материалы для помещения в газете следует отправить в программе Word по электронной почте в адрес griftim@mail.ru.***

***Напоминаем, что редакция не рецензирует материалы, а также не выражает публично свое отношение к содержанию и форме представленных материалов.***

---


| **ГАЗЕТА “ФИКЕР” №2 (115), 2018 год. Электронная версия.<br>Орган Казахстанского конгресса татар и башкир** | |
|---|---|
| Главныйредактор<br>Г.Т.Хайруллин<br>Компьютерная верстка<br>Р.Р.Наратов | Свидетельство о постановке на учет средств массовой информации<br>№13715 от 26 июня 2013 года. Выдано Комитетом архивов Министерства культуры и информации РК |